СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАДУГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 84

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Карадуган авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Карадуган авыл җирлеге Советының 2018 елның №83 «Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын, Карадуган авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендәге «Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында " гы 23 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2019 елда Карадуган авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:
- Кенәбаш авылында: Горная урамы буенча юлларны ремонтлау; Үзәк урамында янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу һәм урнаштыру.;
- Арбаш авылында: h. Такташ, Комсомол урамнары буенча чокырларны ямау; Комсомол урамында янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу һәм урнаштыру;;
- Карадуган авылында Себер тракты урамында асфальт-бетон өслекле җәяүлеләр өчен тротуар урнаштыру; Габдулла Тукай урамында янгынга каршы гидрант һәм

аңа комплектлау әйберләре сатып алу һәм урнаштыру;;
- Тау Зары авылында: Хәтнә елгасы аша асылмалы күперне ремонтлау;
- Түбән Кенә авылында: Ю. Гагарин урамы буенча юлларны ремонтлау; Мәктәп урамында янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу һәм урнаштыру.;
- Югары Кенә авылында зират коймасын ремонтлау; Габдулла Тукай урамында янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу һәм урнаштыру;

Эйе ЮК"

3. Карадуган авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.
4. Әлеге карарны " Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев